

Рус Караево авыл администрациясенә 7 яшәv урыны керә: 263 кеше яшәгән Рус Караевосы һәм 202 кешеле Татар Караевосы, 72 кешеле Сосновка авылы. Тагы 75 кеше яшәгән Пушта поселогы һәм 7 кешеле Росстанье белән ике кешеле Романовский авыллары да Рус Караево администрациясе карамалыгында. Ә Нижний Сатис поселогын дачачылар бик тә ярата. Жирле халкы бу авылнын юк инде, ә аларнын йортларына икенче яшәешне Саровтан килгән торле милләт халкы биргән. Шулай итеп, барлыгы бу администрация карамагында 621 кеше яши: 323 - эшкә яраклысы, 188 пенсионер, 89 бала һәм уналты, алардан олкәнрәк яшьтәге яшvсмер.

Кемнәр кайда эшли икән, шунысы кызыклы, авыл бит. Бюджет олкәсендә 51 кеше хезмәт итә: авыл администрациясендә, фельдшер-акушер пунктында, мәдәният Үзәгендә һәм мәктәптә, П. Г. Смидович исемендәге заповедникта.       Калганнары Темниковнын РЭСында, больницада, ПМКда, соцзащитада, почтада, 6 кеше УФСИНда, 18 - Саров шәһәрендә һәм 28 кеше Мәскәvгә эшкә йориләр. Шулай яши дә авыллар.

Рус Караево авылы диеп аталса да, торле милләт халкы яши бу жирдә. Рус милләтлеләре - 375, татарлар икенче урында - 231, украинлылар - 21, мордвалар - 7, грузиннар - 2, әрмәнле  берәv, хәтта чегән дә икәv бар. Алар vзара дус яши. Дәлил. Рус Караево авылы чиркәvенә нигез салганнар. Зур олеш жирле предприниматель Р. Р. Дулатов керткән: фундаментка блоклар биргән. Жыелган акча житә тошмәсә дә, халыкнын спонсор олешенә ышанабыз, диләр. Бер-берсенә ярдәмләшеп яши авыл.

Бу администрация карамагындагы авылларда яшьләре буенча ин олылар арасында 95 яшен тутырган А. А. Позднякова, 92 яшьлек Е. М. Тябердина һәм Н. А. Бирюкова, 91 яшьлек Е. Ф. Ермошкина бар. Озак яшәvчеләрнен, халыкнын саулыгы тәжрибәле медицина хезмәткәрләре кулында. Алар - 35 ел хезмәт стажлы Н. И. Немова, 25 елдан артык эшләгән Н. С. Кижменева, инде 5 еллап Е. Ф. Комарова эшли. Оста фельдшерлары, укытучылары, мәдәният хезмәткәрләре авылларындагы тормышны эчтәлекле итә. Ә туган туфракларына жаны-тәне белән береккән чын жир хужалары хужалыкларында vгезләр симертәләр, кәжә-сарык vрчетәләр, ә кемдер савым сыерлары санын арттырып, шуннан яхшы гына табыш ала. Рус һәм Татар Караево авылларынын оч кибетендә сот ашамлыклары сатылуга карамастан, бу якларнын тырыш жирле халкы кvбрәк сыерларны vзләре асрый. 246 шәхси хужалыкларда 135 баш могезле хайван асрала. Шуларнын 31 сыеры Татар Карае авылында, 42 - Рус Караенда, 5 - Сосновка авылларында. Ел башыннан алып бvгенге конгә кадәр халык 35 тонна сот сатканнар. Бу администрация территориясендә Ичалки сот һәм сыр заводынын заготовителе бар, шул кабул итә дә инде карайлылар сотен. Югарыда әйтелгән барысы турында 16 ел бу

жирлекләр администрациясен житәкләгән, анын тырыш Главасы Нюрия Абидулла кызы Позднякова телефоннан житкерә һәм корреспондентларга интервью бирә. Шулай, интервьюсынын берсендә күп кешене кызыксындырган сорауга – поселения доходы нәрсәдән барлыкка килә дигән сорауга: « Жирле vзидарәнен бюджеты - эшчәнлекнен барлык социаль олкәләре чагылыш тапкан топ финанс документ ул. Керемнәребез налоглардан тора һәм ел планы итеп кабул ителгән 507,7 мен сумнын 408, 4 мен сумын жыйдык инде. Болар - vзебезнен подоходный налог, имущество налогы, жир налогы һәм башка тор налоглардан тора. Мәсәлән, урта мәктәп, авыл администрациясе, ООО «Колорит» кирпеч заводы һәм башка юридик лицолар налоглары бу.
Товар әйләнмәсе аксаганын да яшермим, ди житәкче. Бу кvрсәткечкә, берничә километр гына ераклыктагы Темников шәһәрендәге кибетләр челтәре булуы, опт базалар эше комачаулый.  Халык алардан сатып алырга ашыга. Сосновка авылы халкына да товарны Темник, Ельник, Краснослободск районы лавкалары китереп сата».
Халыкнын тырыш, булдыклы булуы турында да әйтеп китте житәкче. Хезмәтне яраткан кешеләребез – безнен байлык, ди Темник районы жиде авылга Глава буларак хезмәт итә торган Нюрия Абидулла кызы Позднякова. Алар мал-туар асрый белеп vрчетәләр. Буыннан-буынга кvчә аларнын шул осталыгы. Мисал очен Татар Карай авылында яшәгән Наилә Равиль кызы белән Наиль Амрулла улы Чекашевлар гаиләсен алыйк. Әти-әниләре белән бер хужалыклары аларнын, эштә булдыклы булу һәм мал-туар асраудан чын табыш булдыра алуларын балаларында да тәрбияләгәннәр. Хезмәтне яраткан гаилә йортында жиде vгез һәм оч сыер бар. Тагы ат, тавыклар, казлар vстерәләр. Сонгы 10 айда гына бу гаилә 8 тонна сот сатып, район оештырган «Район хужалыгынын ин яхшысы» дигән конкурста жинvчеләр булдылар. Ильдар уллары - сельхозколледж студенты; әти-әнисенә ярдәм итеп тора. Фермер Чекашевлар династиясе эшен Ильдарлары дәвам итәр дигән фикер бар. Тагы Чекашевлар туган авыллары Татар Караевосы тормышында актив катнашалар. Мәсәлән, Наиль Амрулла улы авылына критик ситуациядән чыгарга ярдәм иткән – водопроводны ремонтларга булышкан.
Авыл Главаларынын кыйбат тора торган проблемаларнын берсе -юлларны ремонтлау һәм тозекләндерv. Быел алар белем, саулык, мәдәният Йортларына бара торган юлга шебень сибеп, грейдер белән тигезләтеп торалар. Администрацияләре янындагы Сугыш батырлары һәйкәленә юлны да тозекләндергәннәр. Яна ел бәйрәме алдыннан ин матур ой һәм матур иттереп бизәлгән йорт конкурсы vткәрергә жыеналар. Житәкче әйтеп киткәненчә, Татар Караево авылы жирләре ин матур жыештырылганнардан берсе. Мона момкинчелек һәм теләк кирәк. Хезмәтне яраткан бу як кешеләрендә ул бар.

**Наилә Насырова**